| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

21.03.2022 Казан ш. № 843-р

Татарстан Республикасы Апас, Әлки муниципаль районнары территориясендә газ бүлү челтәре объектларының саклык зоналарын урнаштыру турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, “Күчемсез милекнең дәүләт теркәве турында” 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль законның 32 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Атлант» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасы пространство мәгълүматы фонды» ДБУ хатын истә тотып (02.03.2022 № 337/04), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Газ бүлү челтәре объектының («ТР, Апас муниципаль районы, Олы Күккүз авыл җирлеге адресы буенча урнашкан Автомобильгә газ тутыру компрессор станциясенә илтүче тышкы газүткәргечләрнең саклык зонасы. Участокның кадастр номеры 16:08:040702:87») 67 м. озынлыктагы саклык зонасын, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, гомуми мәйданы 274 +/- 3 кв.м.лы территория рәвешендә урнаштырырга.

2. Газ бүлү челтәре объектының («ТР, Әлки районы, Аппак авылы, Овражная ур., 11 нче й. адресы буенча урнашкан Автомобильгә газ тутыру

компрессор станциясенә илтүче тышкы газүткәргечләрнең саклык зонасы. Участокның кадастр номеры 16:06:020101:771») 157 м. озынлыктагы саклык зонасын, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, гомуми мәйданы 639 +/- 11 кв.м.лы территория рәвешендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның 1 – 2 пунктларында күрсәтелгән газ бүлү челтәрләренең саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәрләрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җир ресурслары идарәсе башлыгы Н.В. Захаровка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**